| ГЛАВА ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.10.2021 с.Старое Дрожжаное № 44

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында «Казан - Ульяновск» - Иске Чүпрәле» - Зур Чынлы автомобиль юлы төзелеше» объекты буенча территорияне планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Дәүләт казна учреждениесе «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» 2021 елның 13 октябрендәге 7897 номерлы мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2021 елның 27 маендагы 9/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында Гавами тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына ия булучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында, КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында «Казан - Ульяновск» - Иске Чүпрәле» -Зур Чынлы автомобиль юлы төзелеше» объекты буенча территорияне планлаштыру проекты һәм объектны ызанлау проекты составында территорияне планлаштыру документларын карау буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә (алга таба - территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты составында территорияне планлаштыру документлары).

2. Территорияләрне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты составында территорияне планлаштыру буенча документларны карау буенча гавами тыңлаулар оештыруны һәм үткәрүне Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләргә.

3. Билгеләргә:

3.1 гавами тыңлауларны үткәрү вакыты: 2021 елның 08 нояберennән 08 декабренә кадәр;

3.2 гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышының датасы, вакыты һәм урыны:

- 2021 елның 08 декабрендә 09:00 сәгатьтә Мәдәният йортының тамаша залында: Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Зур Чынлы авылы, Ватан ур., 1 й.;

- 2021 елның 08 декабрендә 14:00 сәгатьтә Мәдәният йортының тамаша залында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Кече Чынлы авылы, Крупская ур., 2 й.;

3.3 гавами тыңлауларда катнашу хокукы белән гаризалар бирү вакыты һәм тәртибе 2021 елның 07 декабренә кадәр, эш көннәрендә 08:00 сәгатьтән 12:00 сәгатькә кадәр, 13.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча: 422470, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылы, Үзәк урамы, 13 нче йорт адресы буенча, гражданнар өчен мәҗбүри күрсәтелгән: фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, яшәү урынын теркәү адресын, эш урынын, элемтә өчен телефоннарны күрсәтеп, гражданнар төркеме өчен – фамилияләрен, исемнәрен, әтисенең яки иҗтимагый оешмаларга яки берләшмәләргә (бар икән), яшәү урынын теркәү адреслары, элемтә өчен телефоннар, юридик затлар өчен – оешма бланкында, җитәкченең фамилиясен, исемен, әтисенең исемен күрсәтелеп бирелә.

4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетына:

4.1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: https://drogganoye.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет – телекоммуникация челтәрендә территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты составындагы территорияне планлаштыру буенча документация;

4.2. 2021 елның 08 ноябреннән 07 декабренә кадәр территорияләрне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты составында территорияне планлаштыру буенча документация экспозициясен үткәрү;

4.3. әлеге Карарның 3 пунктында күрсәтелгән чорда, яңа коронавирус йогышы таралуга юл куймау буенча профилактик чараларны исәпкә алып, гавами тыңлаулар үткәрергә;

4.4. гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң 5 көн эчендә территорияне планлаштыру проекты составында территорияне планлаштыру һәм территорияне ызанлау проекты составында территорияне планлаштыру документларын, гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм ахыргы карарны кабул итү өчен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советына гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә җибәрергә.

5. №1 кушымта нигезендә кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем составын төзергә һәм расларга.

6. Территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты составында территорияне планлаштыру документларын халык алдында тыңлауларга чыгарылган тәкъдимнәр һәм искәрмәләр гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан түбәндәге тәртиптә күрсәтелергә мөмкин:

- 2021 елның 08 ноябреннән 2021 елның 07 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылы, Үзәк урамы, 13 нче йорт адресы буенча гавами тыңлауларны оештыручы адресына язма рәвештә;
- гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын уздыру барышында язмача яки телдән.

Территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты составында территорияне планлаштыру буенча документларны карау буенча ачык тыңлауларда катнашучылар булып, әлеге проектлар, әлеге территория чикләрендә булган җир кишәрлекләренә һәм (яки) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына хокук ияләре, шулай ук әлеге капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булып торучы биналарга ия булучылар тора.

7. Әлеге карарны «Туган як» район газетасында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга https://drogganoye.tatarstan.ru/ “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе Д.А. Сатдиновка йөкләнә.

Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы — М. Р. Гафаров

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгының
«27» 10 2021 г. № 44
карарына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында «Казан - Ульяновск» - Иске Чүпрәле» - Зур Чынлы автомобиль юлы төзелеше» объектын ызанлау проекты составында территорияне планлаштыру буенча документларны һәм территорияне планлаштыру проектын карау буенча гавами тыңлаулар барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Сатдинов Д. А. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе - эшче төркем рәисе; |
| Бикчуров И. С. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары-эшче төркем рәисе урынбасары; |
| Фатхеев Ф. Р. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлеге баш белгече - эшче төркем секретаре. |
| Багаутдинов Р.Р. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Ханбиков Б. З. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча); |
| Фатхуллов Ф. З. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Халитов Г. Ш. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Кече Чынлы авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча); |